**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**«Иске Үтәмеш авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлегенең**
**гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Иске Үтәмеш авыл җирлеге составына керүче
Югары Чегодай торак пунктында гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

**14 октябрь 2025 ел** **№ 9**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 14 октябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча йомгаклау беркетмәсе төзелде киләсе мәсьәлә буенча: «2026 елда Иске Үтәмеш авыл җирлегенең Югары Чегодай авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган һәм даими яшәүче кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә, I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, шулай ук мобилизацияләнгән гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрергә ризамы:

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту) Югары Чегодай торак пунктында ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу; Югары Чегодай торак пунктында ике дәүләт телендә (рус һәм татар телләрендә) бертөрле төстәге һәм ясалыштагы урамнарның табличкаларын (күрсәткечләрен) һәм йортларның номерларын әзерләү;
- Югары Чегодай торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- Югары Чегодай торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм җайланмаларның электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен бүтән билгеләнештәге урыннарны ремонтлау (Югары Чегодай торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү, Югары Чегодай торак пунктындагы чишмәләрне ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- Югары Чегодай торак пунктында су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

«РИЗА» «КАРШЫ».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 130 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 90 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 90 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге составына керүче Югары Чегодай торак пунктында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип таныргa.

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2026 елда Иске Үтәмеш авыл җирлегенең Югары Чегодай авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган һәм даими яшәүче кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә, I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, шулай ук мобилизацияләнгән гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрергә ризамы:

**- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту) Югары Чегодай торак пунктында ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу; Югары Чегодай торак пунктында ике дәүләт телендә (рус һәм татар телләрендә) бертөрле төстәге һәм ясалыштагы урамнарның табличкаларын (күрсәткечләрен) һәм йортларның номерларын әзерләү;

- Югары Чегодай **торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;**

- Югары Чегодай торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм җайланмаларның электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен бүтән

билгеләнештәге урыннарны ремонтлау (Югары Чегодай торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);

- **җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү,** Югары Чегодай торак пунктындагы чишмәләрне ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- Югары Чегодай торак пунктында су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу **карар кабул ителгән дип танырга.**

**2.** Әлеге карарны Югары Чегодай авылы, Совет урамы, 25А йорт адресы буенча мәгълүмати стендларда һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлегенең Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

**3.** Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Иске Үтәмеш авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Р.С.Мингулов